**Мэктэпкэчэ яшьтэге балаларнын усешендэ уеннарнын роле**

Мэктэпкэчэ тэрбия учреждениелэренен топ бурычы- балаларны рухи яктан бай, эдэпле, физик яктан сэламэт, кыю итеп устеру. Бу бурычлар торле юллар белэн тормышка ашырыла. Э шулар арасында ин актуаль, ин моhим hэм кыйммэтлесе – уеннар.

Балаларнын hэрьяклап усешендэ уеннарнын эhэмияте зур. Уен аша мэктэпкэчэ яшьтэге балаларга яна белемнэр алу ихтыяжы гади hэм анлаешлы итеп бирелэ. Уен – баланын тормышка эзерлэну кунекмэсе ул, уен- ул белем hэм тэрбия чыганагы. Уеннар баланын шэхес булып формалашуына зур йогынты ясый, психик усешенэ ярдэм итэ, алар нэнилэрдэ бер-берсенэ булышу, дуслык, зирэклек кебек сыйфатлар тэрбияли. Уеннар ярдэмендэ бала кыю, кочле, сэлэтле булып усэ. Шул ук вакытта уен тирэ-юньне танып, ижади кузалларга, фикерлэргэ дэ ойрэтэ торган чыганак. Уенда балалар болар белэн генэ чиклэнмичэ,предметнын тосен, формасын, тэмен, сыйфатын, зурлыгын, нинди материалдан ясалганын да ачыклыйлар. Мэсэлэн, дидактик уен « Нэрсэ,нинди?». Бу уенда балалар яшелчэ яисэ жилэк - жимешнен исемен эйтеп, аларнын тослэрен, формаларын атыйлар

Дидактик уеннар балаларнын уйлау сэлэтлэрен устерэ, эйлэнэ- тирэлекне танып белергэ, эйберлэрнен характерлы узлеклэрен кабул итэргэ, кузаллауны устеругэ ярдэм итэ. Мэсэлэн, дидактик уен «Рэсемне дорес жый». Бу уенда балалар киселгэн рэсемнэрне дорес жыярга тиешлэр. Уеннын бурычы - балаларны логик фикерлэугэ ойрэту, аерым олешлэрдэн тулы бер рэсем жыя белу. Лэкин топ талэп булып рэсемнэрдэге предметлар балаларга таныш булырга тиеш.

Балалар бакчаларынын hэрбер торкемендэ балаларнын яшь узенчэлеклэренэ, сойлэм теленен усешенэ, уйлау сэлэтлэренэ карап уеннарны сайларга кирэк. Уен очен унайлы шартлар тудыру да игътибар узэгендэ торырга тиеш. Уен кирэк-яракларын, кулланмаларны, маскаларны, жиhазларны алдан эзерлэп куярга кирэк. Шул ук вакытта торкемдэге дидактик уеннар hэм уенчыклар балаларга алырлык hэм уйнаганнан сон уз урыннарына куярлык итеп жайлы урында урнашкан булырга тиешлэр.

Уенчыклар, маскалар, кулланмалар, жиhазлар ачык тостэ,матур, балаларнын игътибарларын узлэренэ жэлеп итэрлек булсыннар.Шулай булганда гына балалар уеннын эчтэлеген hэм кагыйдэсен тиз анларга ярдэм итэлэр. Уеннарны сайлаганда балалар алдында авыр яисэ жинел бурычлар торырга тиеш. Эгэр дэ уеннар баланын яшь узенчэлегенэ туры килми икэн, мондый уеннарны алар яратып уйнамыйлар. Яна уеннарны уку- укыту эшчэнлегенэ экренлэп кертергэ кирэк, э шогыльлэрдэ уеннар бер яки икедэн артырга тиеш тугел. Шулай итеп, уеннар тэрбия чарасы буларак, баланын шэхес булып формалашуына зур йогынты ясый.

**Учитель по обучению татарскому языку МБДОУ № 63.**
**Хусаенова Ф.Х.**

